СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

28.06.2024 № 47/4

На № _________ от ______________

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2020 елның 21 октябрендәге 2/11 номерлы карары белән расланган Җирләрне җирле әһәмияттәге рекреацион билгеләнештәге махсус саклanылучы территорияләр җирләренә кертү, аларны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә файдалану һәм саклау тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Җир кодексының 94 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Махсус саклanылучы табигать территорияләре турында» 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Экология кодексы, район уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2020 елның 21 октябрендәге 2/11 номерлы карары белән расланган Җирләрне җирле әһәмияттәге рекреацион билгеләнештәге махсус саклanылучы территорияләр җирләренә кертү, аларны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә файдалану һәм саклау тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Рекреацион билгеләнештәге җирләргә рекреацион эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кулланыла торган җирләр керә (туризм, физик культура һәм спорт өлкәсендә эшләр башкару һәм хезмәтләр күрсәтү, гражданнарның ялын һәм сәламәтлеген ныгытуны оештыру).

Рекреацион билгеләнештәге җирләрдә рекреацион эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән объектлар булдыру рөхсәт ителә. Мондый объектлар исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

Җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир хуҗалары һәм җир кишәрлекләрен арендалаучылар белән килешү буенча урнаштырылган юллардан,

сукмаклардан һәм трассалардан файдалану сервитутлар нигезендә гамәлгә ашырылырга мөмкин; шул ук вакытта әлеге җир кишәрлекләре файдаланудан алынмый.

Рекреацион билгеләнештәге җирләрдә, мондый җирләрне һәм аларда урнашкан объектларны саклау һәм куллануның билгеләнгән режимын, шул исәптән җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалануны, рөхсәт ителгән төзелешне үтәгәндә, хуҗалык эшчәнлеге рөхсәт ителә.».

1.2. 3, 4 пунктлары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (https://tukay.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы,
Совет Рәисе урынбасары Р.И. Закиров